ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.10.2024 Олы Кайбыч ав. № 389

«Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 321 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 22 июлендәге 194-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 321 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кушымтаның 2.8.3.2 пунктында:

а) 8 пунктчада «территорияне комплекслы үстерү» сүзләреннән соң «яисә, күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән» сүзләрен өстәргә;

б) 9 пунктчада «территорияне, яисә» сүзләрен «күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта территорияне йә аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителде, яисә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 10 пунктчада «территорияне, һәм» сүзләрен «территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәгән очракта, территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан территорияне, яисә территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территорияне» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров